КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 15 октябрь г.Казань № 885

«Әкият» татар дәүләт курчак театры» дәүләт бюджет учреждениесенә «Академия» исемен бирү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт театрларына һәм концерт оешмаларына «Академия» исемен бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 9 октябрь, 962 нче карары нигезендә Татарстан Республикасы мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренең иҗади коллективларын стимуллау, үстерү һәм аларга ярдәм күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының түбәндәге тәкъдимнәрен кабул итәргә:

«Әкият» татар дәүләт курчак театры» дәүләт бюджет учреждениесенә «Академия» исемен бирү турында;

«Әкият» татар дәүләт курчак театры» дәүләт бюджет учреждениесе исемен «Әкият» татар дәүләт академия курчак театры» дәүләт бюджет учреждениесенә (алга таба – Учреждение) үзгәртү турында.

2. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына 60 көн эчендә Учреждение уставына тиешле үзгәрешләрне кертергә һәм билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин